**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Иске Кәшер авыл җирлегенең Яхшыбай авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**18 ноябрь 2022 ел** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 19 ноябрендә 15.00 сәгатьтә үткәрелгән гражданнар җыенының «2023 елда 300 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Кәшер авыл җирлеге территориясендә , I төркем инвалидлар; тыл хезмәтчәннәре; көндезге бүлек студентлары; хәрби хезмәт һәм контракт буенча үтүче гражданнар; мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме:

- Җиңү көне, Сабантуй, өлкәннәр көне ,инвалидлар коне , Яңа ел бәйрәмнәрен үткәрү өчен бүләкләр,- светодиод яктырткычлар урнаштыру;
- МТЗ-82 тракторын карап тоту( ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу););
- авыл җирлеге торак пунктларындагы юлларны кыш көне кардан чистарту, җәйге вакытта үләннәрне чабу, төзекләндерү буенча хезмәт күрсәтүчеләргә хезмәт күрсәтү өчен түләү.);- - Яхшыбай авылы зираты коймаларын янарту очен материал сатып алу; - «Сарман»район газетасына некрологларны бирү.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 60 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 35 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен 35 катнашучы тавыш бирде;
«КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Иске Кәшер авыл жирлегенең Яхшыбай авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип таныргa, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип таныргa.
2. «2023 елда 300 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Кәшер авыл җирлеге территориясендә I төркем инвалидларыннан, ялгыз карт гражданнардан, көндезге уку йортлары студентларыннан, хәрби хезмәттәге хәрбиләрдән тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган

кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме» дигән сорау буенча карар кабул итәргә:

- - Җиңү көне, Сабантуй, өлкәннәр көне ,инвалидлар коне , Яңа ел бәйрәмнәрен үткәрү өчен бүләкләр,
- светодиод яктырткычлар урнаштыру;
- МТЗ-82 тракторын карап тоту( ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу););
- авыл җирлеге торак пунктларындагы юлларны кыш көне кардан чистарту, җәйге вакытта үләннәрне чабу, төзекләндерү буенча хезмәт күрсәтүчеләргә хезмәт күрсәтү өчен түләү.);-
- Яхшыбай авылы зираты коймаларын янарту очен материал сатып алу;
- «Сарман»район газетасына некрологларны бирү.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Иске Кәшер авыл җирлегенең Яхшыбай мәгълүмати стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Иске Кәшер авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Сарман муниципаль районы
Иске Кәшер авыл җирлеге башлыгы,
Халык җыенында рәислек итүче Р.Н. Дәүләтҗанов